ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.05.2026 Олы Кайбыч ав №218

Кайбыч муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаучылар, шул исәптән һәлак булган (вафат булган) махсус хәрби операциядә катнашучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия төзү турында

«Ватанны саклаучыларның истәлеген мәңгеләштерү турында»1993 елның 14 гыйнварындагы 4292-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә тарихи дөреслекне саклау, гражданнарга патриотик тәрбия бирү, шулай ук исән һәм һәлак булган Ватанны саклаучыларга рәхмәт һәм хөрмәт белдерү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. Кайбыч муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаучылар, шул исәптән һәлак булган (вафат булган) махсус хәрби операциядә катнашучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия төзергә һәм аның составын расларга (1нче кушымта).

2. Кайбыч муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаучылар, шул исәптән һәлак булган (вафат булган) махсус хәрби операциядә катнашучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия турында нигезләмәне расларга. (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

4. . Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның «14» 05
218 номерлы карарына
1 нче кушымта

Кайбыч муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаучылар, шул исәптән һәлак булган (вафат булган) махсус хәрби операциядә катнашучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Петухова Ф.Ф. | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе; |
| Заһидуллина Э.Х. | Кайбыч муниципаль районы Башлыгы урынбасары, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Ворожейкина А.В. | Кайбыч муниципаль районының "Форпост" җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләре үзәге" МБУ директоры, комиссия секретаре; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Михайлова Л.Г. | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе; |
| Давыдова Е.Г. | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча урынбасары |
| Тимершина С.Б. | Татарстан Республикасы хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кайбыч муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Шәрәфиева Р.Р. | Татарстан Республикасы буенча «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү Дәүләт фонды филиалының Кайбыч районындагы социаль координаторы; |
| Насыйбуллина Р.Д. | Кайбыч районында «Юнармия» Бөтенроссия хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәте җирле бүлекчәсе штабы башлыгы (килешү буенча); |
| Лотфуллина Р.Г. | «Кайбыч муниципаль районы ветераннар һәм |

| | |
|---|---|
| | пенсионерлар Советы» иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча); |
| Җантимеров Н.Ш. | Татарстан Республикасы Апас һәм Кайбыч районнары хәрби комиссары (килешү буенча); |
| Әбләзова Р.Р. | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы; |
| ________________ | Кайбыч муниципаль районының авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның «14» 05
218 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Кайбыч муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаучылар, шул исәптән һәлак булган (вафат булган) махсус хәрби операциядә катнашучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Кайбыч муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаучылар, шул исәптән һәлак булган (вафат булган) махсус хәрби операциядә катнашучылар истәлеген мәңгеләштерү комиссиясе турында нигезләмә (алга таба – нигезләмә) комиссиянең (алга таба - Комиссия) вәкаләтләрен һәм эш тәртибен билгели.

1.2. Комиссия Кайбыч муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаганда һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләрен объектив карау һәм хәл итү максатларында төзелгән даими эшләүче коллегиаль киңәшмә органы булып тора.

1.3. Комиссия үз эшчәнлегендә «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, «Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү турында» 1993 елның 14 гыйнварындагы 4292-1номерлы Россия Федерациясе Законы, «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында совет халкының җиңүен мәңгеләштерү турында» 1995 елның 19 маендагы 80-ФЗ номерлы, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эш итә.

1.4. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 2. Комиссия компетенциясе

2.1. Гражданнардан, оешмалардан һәм башка иҗтимагый берләшмәләрдән кергән гаризалар, мөрәҗәгатьләр нигезендә Комиссия Кайбыч муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләрен карый һәм карарлар кабул итә.

2.2. Комиссия Кайбыч муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр инициаторы булырга хокуклы.

## 3. Комиссия хокуклары

3.1. Комиссия үз вәкаләтләре чикләрендә Комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен, коллектив мөрәҗәгатьләрне карый.

3.1.2. үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләне караганда Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

3.1.2.1. чыгарылган мәсьәлә буенча уңай карар кабул итәргә;

3.1.2.2. мөрәҗәгать итүченең үтенечен канәгатьләндерүдән дәлилләп баш тартырга;

3.1.2.3.карар кабул итүне кирәкле документлар бирелгәнче йә мәсьәләне өстәмә өйрәнү өчен кичектерергә;

3.1.2.4. мөрәҗәгатьне мөрәҗәгать итүче барында карарга;

3.1.2.5. комиссия каравына тапшырылган документлардагы белешмәләрне тикшерү өчен эш төркемнәре төзергә;

3.1.3. комиссия кабул ителгән карарлар турында кызыксынган якларга хәбәр итәргә.

## 4. Комиссия составы һәм эш тәртибе

4.1. Комиссия төзү, аның персональ составын раслау һәм үзгәртү турында карар Кайбыч муниципаль районы башлыгы карары белән кабул ителә. Комиссия составына комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретарь һәм комиссиянең кимендә дүрт әгъзасы керә.

4.2. Комиссия рәисе Комиссия утырышлары үткәрә, аның эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итә, рәис урынбасары, секретарь һәм комиссия әгъзалары арасында бурычларны бүлешә, аларның эшчәнлеген координацияли һәм комиссиягә йөкләнгән функцияләрне башкару өчен җаваплы була.

4.3. Рәис урынбасары комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм рәис булмаганда комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була.

4.4. Комиссия секретаре утырышка материаллар әзерләүне, утырыш беркетмәләрен алып баруны тәэмин итә һәм комиссия эшчәнлеген тәэмин итү буенча башка функцияләрне башкара.

4.5. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма елына кимендә ике мәртәбә уздырыла. Комиссия утырышын үткәрү мәсьәләләре исемлеген, вакытын һәм урынын комиссия рәисе билгели. Комиссия әгъзаларына чираттагы утырышның датасы, урыны һәм көн тәртибе турында аны үткәрү датасына кадәр ике көннән дә соңга калмыйча секретарь тарафыннан хәбәр ителергә тиеш.

4.6. Чираттан тыш утырыш уздырылган очракта комиссия әгъзаларына аны уздыруга бер көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителергә тиеш.

4.7. Комиссия утырышларына оешмаларның һәм учреждениеләрнең җаваплы хезмәткәрләре, шулай ук карала торган мәсьәләләрнең асылы буенча үтенеч белән мөрәҗәгать итүче гражданнар чакырылырга мөмкин.

4.8. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

4.9. Комиссия утырышлары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәдә утырышны үткәрү датасы, карала торган мәсьәләләрнең кыскача эчтәлеге, алар буенча кабул ителгән карарлар, карала торган конкрет мәсьәләләр буенча комиссия әгъзаларының аерым фикерләре күрсәтелә. Чыгарылган мәсьәләләр буенча уңай карарлар кабул ителгән очракта, комиссия Кайбыч муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаганда һәлак булганнарны мәңгеләштерү чараларын финанслау чыганагын билгели.

4.10. Утырыш беркетмәсенә утырышта катнашкан барлык комиссия әгъзалары имза сала һәм Идарәдә саклана.

## 4. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Әлеге Нигезләмәдә чагылыш тапмаган мәсьәләләр Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә хәл ителә.